Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Мамадыш районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Мамадыш районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 119-ТРЗ

«Татарстан Республикасы
Мамадыш районы буенча
Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш районы буенча**
**Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының**
**суд участоклары чикләре**
**тасвирламасы**

## 1 нче суд участогы

1 нче суд участогы чигенә «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көнбатыш чиге һәм Ушма елгасы кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, сул ярны кертеп, елга үзәне буйлап көнчыгышка таба «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Отарка авыл җирлеге белән чигендә урнашкан, Ушма елгасы Нократ елгасына койган ноктага кадәр уза, алга таба «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап төньякка таба шәһәрнең көнбатыш чиге һәм Ушма елгасы кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма, Дүсмәт, Ишки, Көмешкүл, Келәүш, Көек-Ерыкса, Малмыж, Кече Кирмән, Түбән Ушма, Түбән Тәкәнеш, Түбән Шүләңгер, Никифорово, Олыяз, Урта Кирмән, Тауиле, Шәдче һәм Шәмәк авыл җирлекләре.

## 2 нче суд участогы

2 нче суд участогы чигенә «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге шәһәрнең көнбатыш чиге һәм Ушма елгасы кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, уң ярны кертеп, елга үзәне буйлап көнчыгышка таба «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлегенең Отарка авыл җирлеге белән чигендә урнашкан, Ушма елгасы Нократ елгасына койган ноктага кадәр уза, алга таба «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап көньякка таба шәһәрнең көнбатыш чиге һәм Ушма елгасы кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Мамадыш муниципаль районының Албай, Дегетле, Катмыш, Красная Горка, Керәшен Пакшины, Түбән Сон, Омар, Отарка, Рагозино, Сикәнәс, Соколка, Сон, Уразбахты, Урманчы, Усали һәм Яке авыл җирлекләре.